| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

27.01.2025 п.г.т.Алексеевское № 23-р

**2025 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында**

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансслы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 07 сентябрендәге 1099 номерлы «2024-2026 елларга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2024 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны бушлай кайнар туклану белән тәэмин итү һәм оештыру өчен норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар тукланунның уртача бәясен раслау турында» карарын исәпкә алып,«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлеше, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 6 өлеше, 20.10.2022 ел, № 1122 «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 14.11.2022 ел, № 1213 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20.10.2022 № 1122 карарына үзгәрешләр кертү турында» карарларын игътибарга алып:

1. 2025 елның гыйнварыннан Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1. Төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны 9 сум 60 тиен күләмендә җирле бюджет акчаларыннан һәм көненә бер укучыга ата-ана түләвеннән торган суммага кайнар азык белән туклandыруны оештырырга.

1.2. Башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларга көненә бер укучыга 69 сум 43 тиен күләмендә түләүсез кайнар азык белән туклану оештырырга (Кушымта).

1.3. Районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә бушлай кайнар ризык, тулы күләмдә иртәнге ашлар ашату оештырырга:

- үз составында 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләрдән укучылар өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) күп балалы гаилә таныклыгының күчермәсен тапшырып язылган гариза нигезендә,

- үз составында 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган, РФ гражданлыгы булмаган, әмма Алексеевск муниципаль районы территориясендә яшәүче гаиләләрдән укучылар өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) балаларга туу турында таныклыкларның күчермәсен тапшырып язма гариза нигезендә;

- 18 яшькә кадәрге авыр тормыш хәлендә булган гаиләләрдәге балалар өчен, ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) гаиләдәге хәлне тасвирлаган язма гариза нигезендә, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе, сыйныф җитәкчесе һәм әлеге җирлек башлыгы имзасы белән гаиләнең көнкүреш шартлары акты,гаризаларына кушымта.

- 18 яшькә кадәрге күп балалы тәрбиягә алынган һәм опекун гаиләләреннән укучылар өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) бала туу турында таныклык һәм опека һәм попечительлек бүлеге документларының күчермәсе белән язма гариза нигезендә.

1.4. Районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә тулы күләмдә бушлай кайнар ризык (иртәнге аш) ашату оештырырга:

- Алексеевск муниципаль районынан Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрбиләр һәм затлар гаиләләреннән, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга», «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтәүче, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнарның укучылары өчен, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ карары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы хәрби комиссары имзасы белән мобилизацияләнгән гражданнар исемлеге һәм Алексеевск муниципаль районы башлыгының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2022 елның 17 октябрендәге 122-р номерлы, «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында» 2022 елның 26 декабрендәге 144-р номерлы күрсәтмәләре нигезендә.

1.5. Бер тапкыр ашату өчен билгеләнгән бәядән 50% ташлама белән бушлай кайнар ризык ашату оештырырга (иртәнге аш):

- Алексеевск районы буенча ВСБ хезмәткәрләренең балалары өчен - «Россиянең Татарстан Республикасы буенча МГГ ВСИ» ФДКУ филиалы, ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) язылган гариза һәм Татарстан

Республикасы Алексеевск районы буенча ВСБ җитәкчесе имзасы белән расланып бирелгән исемлекләр нигезендә;

- Россиянең Алексеевск муниципаль районы буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәрләренең балалары өчен, ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) язылган гариза һәм Татарстан Республикасы Алексеевск районы буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең җитәкчесе имзасы белән расланган исемлекләр нигезендә.

1.6 Районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә ике тапкыр бушлай кайнар ризык, иртәнге аш, төшке аш ашатуны тулы күләмдә оештырырга:

-мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) язылган гариза нигезендә, мөмкинлекләре чикләнгән укучының (мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия инвалид баланың) статусын раслаучы документ белән.

1.7. Мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны, өйдә белем алучы инвалид балаларны, ай саен коры паек белән киләсе айның унынчы көненнән дә соңга калмыйча тәэмин итәргә, шул исәптән ике тапкыр түләүсез туклануны уку көннәре өчен акчалата компенсация белән алмаштыру мөмкинлеген, түләүсез ике тапкыр туклануны СМЧ һәм инвалид-балага акчалата компенсация белән алмаштыру турында гариза нигезендә карарга.

1.8. Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә үз составында 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләрдән, 18 яшькә кадәрге аз тәэмин ителгән гаиләләрдән булган балалардан бушлай кайнар туклануны оештыру өчен, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылардан ике тапкыр бушлай кайнар туклануны оештыру өчен, күп балалы тәрбиягә алынган һәм опекун гаиләләреннән, бер тапкыр бушлай кайнар туклану өчен, хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән балалар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән һәм Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче затларның баларыннан, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга», «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтәүче,хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар балалары бер тапкыр бушлай кайнар туклануны оештыру өчен сан составын исәпкә алуны тәэмин итәргә.

1.9. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турындагы мәгълүмат социаль өлкәдә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада һәм БЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштырыла.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Е.М. Мифтахова) 2025 елга чыгымнар сметасында үз составында 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләрдән, аз тәэмин ителгән гаиләләрдән, 18 яшькә кадәрге күп балалы тәрбиягә алынган һәм опекун гаиләләреннән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрбиләрнең гаиләләреннән һәм затларыннан, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче, Татарстан Республикасында оештырылган, махсус

операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче «Алга», «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы буенча ВСБ хезмәткәрләре балалары – «Татарстан Республикасы буенча Россия МГГ ВСИ» ФДКУ филиалы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәрләре балалары туклану өчен акча бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ (В.Ю. Рыдаев):

3.1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында кайнар туклану сыйфаты нормаларын үтәүне исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МБУ җитәкчесенә укучыларның кайнар туклануын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылуын контрольдә тотуны тәэмин итәргә (Н.А.Крохина).

5. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклындыруны оештыру турында» 2024 елның 26 гыйнварындагы 35-р номерлы, 2024 елның 22 мартындагы 140-р номерлы «2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклындыруны оештыру турында «26.01.2024 елгы 35-р номерлы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгына үзгәрешләр кертү хакында»,«2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклындыруны оештыру турында «26.01.2024 ел, № 35-р Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карамагына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 11 сентябрендәге 507-р номерлы боерыклары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тоту Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
27.01.2025 № 23-р
карарына кушымта

| № т/б | Белем бирү учреждениесенең исеме | 7 яшьтән 10 яшькә кадәр көнгә 1 бала өчен иртәнге аш бәясе | 11 яшьтән 18 яшькә кадәр көнгә 1 бала өчен иртәнге аш бәясе |
|---|---|---|---|
| 1. | МБГББО А. А. Малафеева исемендәге 1 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе | 69,43 | 78,00 |
| 2. | МБББО Советлар Союзы Герое И. Е. Кочнев исемендәге 2 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе | 69,43 | 78,00 |
| 3. | МБББО Г. С. Боровиков исемендәге 3 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе. | 69,43 | 78,00 |
| 4. | МБББО Алексеевск 4 нче БББО | 69,43 | 78,00 |
| 5. | МБББО «Биләр УГББМ» | 69,43 | 78,00 |
| 6. | МБББО «Зур Полянка ТГББМ» | 69,43 | 78,00 |
| 7. | МБББО «Зур Тигәнәле ТГББМ» | 69,43 | 78,00 |
| 8. | МБББО «Зирекле ТГББМ» | 69,43 | 78,00 |
| 9. | МБББО «Красный Баран ТГББМ» | 69,43 | 78,00 |
| 10. | МБББО Куркул УГББМ | 69,43 | 78,00 |
| 11. | МБББО «Лебедино ТГББМ» | 69,43 | 78,00 |
| 12. | МБББО «Левашево ТГББМ» | 69,43 | 78,00 |
| 13. | МБББО Юеш Көрнәле УГББМ | 69,43 | 78,00 |
| 14. | МБББО Урман Асты Шонталасы ТГББМ | 69,43 | 78,00 |
| 15. | МБББО Кыр Шонталы ТГББМ | 69,43 | 78,00 |
| 16. | МБББО Речное ТГББМ | 69,43 | 78,00 |
| 17. | МБББО Родники УГББМ | 69,43 | 78,00 |
| 18. | МБББО Ромодан УГББМ | 69,43 | 78,00 |
| 19. | МБББО «Сахаровка ТГББМ» | 69,43 | 78,00 |
| 20. | МБББО Урта Тигәнәле УГББМ | 69,43 | 78,00 |
| 21. | МБББО Чуваш Майнасы ТГББМ | 69,43 | 78,00 |
| 22. | МБББО «Шәмә ТГББМ» | 69,43 | 78,00 |
| 23. | МБББО «Ялкын ТГББМ» | 69,43 | 78,00 |